СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**«04» октябрь 2016 ел** **№24**

## Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

### Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 30 сентябрендәге 19 номерлы «референдум үткәрүне оештыру турында» гы Карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 22 номерлы «референдум үткәрүне оештыру турында» гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

   «2017 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Наименование вопроса местного значения | Запланированные мероприятия |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге; | - юлларга вак таш салу.:<br>Яңа Кырлай авылы, Тукай урамы, 70тән 95кә кадәр; Яшел урамы, Яшьләр урамы;<br>Яңа Иябаш авылы, Татарстан ур., Яшьләр ур.;<br>Өчиле авылы, Яңа ур., Җиңүнең 65 еллыгы ур.;<br>Чиканас авылы, Совет ур., Октябрь ур., 27-51;<br>Иске Юрт авылы, Аркылы ур., Клуб ур.;<br>Югары Бирәзә авылы, Комсомол ур., Бахча-Сарай ур.;<br>Күкчә-Бирәзә авылы, Үзәк ур., 1-11, Починок ур. |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай ур., 73 йорт) мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров